| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.07.2020 № 465-пр

Казан ш.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2020 елның 08 маендагы № 279-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан карарлар кабул ителү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы № 393 карары белән расланган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенең гомуми таләпләренә үзгәрешләр кертүгә бәйле боерам:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2020 елның 08 маендагы № 279-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Җир

һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан карарлар кабул ителү тәртибенә (алга таба – тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- шәхси эшмәкәр булган гражданин - бюджетка түләүченең мөлкәтенә конкурс производствосы тәмамлануы турында яисә реализацияләнеп бетүе турында суд акты;»;

түбәндәге эчтәлекле бишенче абзацны өстәргә:

«- хәлле булмавы (банкротлыгы) танылу турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә бюджетка түләүче шәхси эшмәкәрнең банкрот дип танылуы аркасында эшчәнлегенең туктатылуы турында хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматларын эченә алган документ.»;

6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- бюджетка түләүченең – гражданинның мөлкәтенә конкурс производствосы тәмамлануы турында яисә реализацияләнеп бетүе турында суд акты.»;

8 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерү мөмкинлеген югалтуына китергән штраф яки суд акты рәвешендә җәзага тартылганнарга мөнәсәбәтле амнистия турында яки аклау турында суд акты.»;

9 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару сәбәпле суд приставы-башкаручының карары.»;

10 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- регистрация ясаучы орган карары буенча бурычлының - юридик затның күрсәтелгән ресстрдан чыгарылуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестры мәгълүматларын үз эченә алган документ;»;

түбәндәге эчтәлекле бишенче абзацны өстәргә:

«- бурычлыны хәлле булмавы (банкротлыгы) танылу турында гаризаны кире кайтару турында яки банкротлык турында эш процедураларын үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен акчалар булмау сәбәпле банкротлык турында производствоны туктату турында суд акты.»;

16 пунктның «б» подпунктында «физик зат» сүзеннән соң «(булган очракта) сүзләрен өстәргә;»;

Тәртипнең 2 нче кушымтасында Бурычларны түләттерүне өметсез дип тану турында акт формасының преамбуласында «(физик затның салым түләүче идентификацион номеры» сүзләренә «(булган очракта» сүзләрен өстәргә

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**